Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
2) Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы;
3) Шәһәр төзелеше регламентлары.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

Ачык тыңлаулар 23.01.2026дән 12.02.2026 га кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
-гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;
-проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә, Түбән Чыршылы, Югары Чыршылы, Мордва Ивановка авылларында үткәрелә.

2026 елның 29 гыйнвареннән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының экспозициясен, гавами тыңлауларда карау өчен, авыл җирлеге администрациясе бинасында ачарга.
- ТР, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт;
шулай ук Югары Чыршылы авылы, Таулы урамы, 27 йорт; Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт.

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 29.01.2026 дан 09.02.2026 га кадәр.

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Экспозиция эше барышында «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге адрес буенча кертергә тәкъдим итәргә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт яисә Hayrullina.Nuriya@tatar.ru, Alfiya.Valeeva1@tatar.ru 2026 елның 9 февраленә кадәр, яисә 2026 елның 12 февралендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында катнашучыларны исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып куюю юлы белән.

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

2026 елның 12 февралендә 16.00 сәгать 30 минутта түбәндәге адрес буенча: Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт;

2026 елның 12 февралендә 17.00 сәгать 30 минутта түбәндәге адрес буенча: Югары Чыршылы авылы, Таулы урамы, 27 йорт;

2026 елның 12 февралендә 18.00 сәгать 30 минутта түбәндәге адрес буенча: Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт

2026 елның 29 гыйнварына кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт; Югары Чыршылы авылы, Горная урамы, 27 йорт; Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
"Түбән Чыршылы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
башлыгы Хәйруллина Н.Я.